# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегенең Бишбатман авылы торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

**2023 елның 24 ноябре** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегенең Бишбатман авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегенең Бишбатман авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан тыш, 37000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Үзәк урам буенча Бишбатман авылына автомобиль юлын асфальтлау (асфальтны сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү);
- смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгы ________ И.М. Саттаров
(имза)